ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.02.2021 г. Заинск № 124

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануыноештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә, бюджет акчаларын нәтиҗәле файдалану максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 31 августындагы 378 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталындаhttp://pravo.tatarstan.ruвеб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
5.Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет
җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Л.Р.Печина
3-27-42

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**«27» 02. 2021 ел**
**124 номерлы карарына**
**кушымта**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын**
**оештыру тәртибе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

**2021 ел**

# 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1.Әлеге нигезләмә укучыларның кайнар ризык белән тәэмин ителүен оештыру һәм финанс белән тәэмин итү тәртибен, тукклануны оештыру процессында катнашучыларның хокукларын һәм бурычларын, туклануны оештыруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен, шулай ук Татарстан Республикасы Зәй шәһәре һәм Зәй муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә белем алучы аерым категорияләр өчен социаль ярдәм чараларын билгели.

1.2.Нигезләмә түбәндәгеләргәнигезләнеп эшләнде:

- «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;
- «Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында» 2000 елның 02 гыйнварындагы29-ФЗ номерлы Федераль закон;
- «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон;
- «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон;
- «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон;
- «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 08 декабрендәге 63 номерлы Россия Федерациясе Законы;
- Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 1992 елның 05 маендагы 431 номерлы Указы;
- «Өйдә белем алучы балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) компенсация түләү турында» 2016 елның 14 гыйнварындагы 07-81 номерлы Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы хаты;
- «Төргәкләү иминлеге турында»ТР Таможня берлегенең техник регламенты, 005/2011;
-«Иминлек һәм азык-төлек продукциясе турында»ТР Таможня берлегенең техник регламенты, 021/2011;
-«Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр»СанПин 2.3/2.4.3590-20;
- «Эчә торган су. Эчә торган су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларының сыйфатына карата гигиена таләпләре. Сыйфат контроле. Кайнар су белән тәэмин итү системасының иминлеген тәэмин итүгә гигиена таләпләре»СанПин 2.1.4.1074-01;
- "Санитар кагыйдәләрнең үтәлешен һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактик) чараларны оештыру буенча производство контролен оештыру һәм үткәрү»СП 1.1.1058-01;
-"Җәмәгать туклануы продукциясенең сыйфатын органолептик бәяләү методы»ГОСТ 31986-2012;
- «МР 2.4.0179-20. 2.4. Балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы. Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру буенча тәкъдимнәр. Методик тәкъдимнәр»(РФ баш дәүләт санитар табибы раслаган, 18.05.2020 ел.)
-«МР 2.4.0180-20. 2.4. Балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы. Гомуми белем бирү оешмаларында балаларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру буенча

ата-аналар контроле. Методик тәкъдимнәр»(РФ баш дәүләт санитар табибы раслаган, 18.05.2020 ел.) алга таба «МР 2.4.0180-20».

1.3.Әлеге нигезләмәнең гамәлдә булуы гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы барлык укучыларга, шулай ук өйдә белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга кагыла.

## 2. ТӨП МАКСАТЛАР ҺӘМ БУРЫЧЛАР

2.1. Сәламәт туклану сәламәт милләтне формалаштыру һәм актив гомер озынлыгын арттыру өчен бик мөһим.

Сәламәт туклану - көндәлек рационы сәламәт туклану принципларына нигезләнгән, куркынычсызлык таләпләренә җавап бирә һәм физик һәм интеллектуаль үсеш, кешенең һәм киләчәк буыннарның тормыш эшчәнлеге өчен шартлар тудыра торган туклану.

Сәламәт туклану принциплары булып кеше һәм киләчәк буыннарның сәламәтлеген ныгытуга, авырулар үсеше куркынычын киметүгә ярдәм итә торган төп кагыйдәләр һәм нигезләмәләр тора һәм үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- азык-төлек продуктлары белән эш итү белән бәйле эшчәнлек алып баручы индивидуаль эшмәкәрләрнең һәм юридик затларның икътисадый мәнфәгатьләренә каратаазык-төлек продуктларын кулланучыларның тормышын һәм сәламәтлеген яклауның өстенлеген тәэмин итү;
- көндәлек рационның энергетик кыйммәтләренең энергия чыгымнарына туры килүе;
-көндәлек рационның химик составының макронутриентларда (аксым һәм аминокислоталар, майлар һәм май кислоталары, углеводлар) һәм микронутриентларда (витаминнар, минераль матдәләр һәм микроэлементлар, биологик актив матдәләр) кешенең физиологик ихтыяҗларына туры килүе;
-көндәлек рацион составындабаетылган майлар (майлы кислоталарның трансизомерларын да кертеп) аз катнаштырылган, гади шикәр һәм аш тозлары, шулай ук витаминнар, азык җепселләре һәм биологик актив матдәләр белән баетылган азык продуктларының булуы;
- мөмкин кадәрмаксималь сәламәт туклануны һәм аның оптималь режимын тәэмин итү;
- азык-төлек продуктларының башлангыч азык кыйммәтен саклауны тәэмин итә торган технологик һәм кулинар эшкәртүне куллану;
- азык-төлек продуктлары (әзер ризыклар) әйләнешенең барлык этапларында санитар-эпидемиологик таләпләрне үтәүне тәэмин итү;
- фальсификацияләнгән азык продуктларын кулланмау.

Сәламәт туклану ашказаны-эчәк тракты, эндокрин система патологиясе формалашу куркынычын, йөрәк-кан тамырлары авыруларын һәм артык гәүдә авырлыгын киметүгә юнәлдерелгән.

Шулай итеп, гомуми белем бирү учреждениесендә укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештырганда төп максатлар һәм бурычлар булып тора:

2.1.1.Укучыларны кайнар аш белән тәэмин итү организмны азык-төлек матдәләрендә һәм энергиясендә физиологик яшь үзенчәлекләренәтуры килә торган кирәкле матдәләр белән тәэмин итәрдәй рациональ, балансслы туклану принципларын формалаштыруга юнәлдерелгән;

2.1.2. Туклануның,ризык әзерләү өчен кулланыла торган азык-төлек продуктларының гарантияләнгән сыйфаты һәм куркынычсызлыгы;

2.1.3.Укучылар арасында туклану факторы белән бәйле йогышлы һәм йогышлы булмаган авыруларны кисәтү (профилактикалау);

2.1.4.Тулы кыйммәтле һәм сәламәт туклану принципларын пропагандалау;

2.1.5.Укучыларны кайнар аш белән тәэмин иткәндә бала сәламәтлегенең үзенчәлекләрен исәпкә алу;

2.1.6.Укучыларга социаль ярдәм күрсәтү:җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләрдән, шул исәптән күпбалалы гаиләләрдән; инвалид балалар һәм өйдә белем алучы инвалид балалар;

2.1.7.Укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруга бүлеп бирелә торган бюджет акчаларыннан гамәлдәге закон таләпләре нигезендә файдалану.

## 3. УКУЧЫЛАРНЫ ТУКЛАНДЫРУНЫ ОЕШТЫРУНЫҢ ГОМУМИ ПРИНЦИПЛАРЫ

3.1.Укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру гомуми белем бирү учреждениесе эшчәнлегенең аерым мәҗбүри юнәлеше булып тора.Мәгариф учреждениеләре һәмтуклануны оештыру буенча хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук азык-төлек продуктлары белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручылар арасында үзара мөнәсәбәтләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелгән контракт (шартнамә) белән җайга салына.Мәгариф учреждениеләре өчен азык-төлек продуктларын сатып алу «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.2.Укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру өчен түбәндәге юнәлешләр буенча санитар-гигиена нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә туры килә торган махсус биналар (азык-төлек блогы) файдаланыла:

3.2.1. Суыру җиһазлары булу, аларның эшләп торуы;

3.2.2.Азык-төлек блогында азык-төлек саклау өчен ярдәмче биналар булу;

3.2.3.Кухня һәм аш бүлмәсе, аш-су приборлары белән тиешле күләмдә тәэмин ителү.

3.2.4.Техник халәте билгеләнгән таләпләргә туры килә торган технологик җиһазлар белән тәэмин ителеш. Нинди дә булса технологик җиһаз сафтан чыккан очракта, менюга үзгәрешләр кертелә;

3.2.5. Яңа уку елы башланыр алдыннан технологик җиһазларның төзеклегенә техник контроль үткәрү;

3.3.Азык-төлек блогында даими булырга тиеш:

-туклануга заявкалар;

- гигиена журналы (хезмәткәрләрнең) (1 кушымтаСанПин 2.3/2.4.3590-20);

-суыткыч җиһазларның температура режимын исәпкә алу журналы(2 кушымтаСанПин 2.3/2.4.3590-20);

-склад биналарында температураны һәм дымлылыкны исәпкә алу журналы (3 кушымтаСанПин 2.3/2.4.3590-20);

-әзер азык-төлек продукциясенең бракераж журналы (4 кушымта СанПин 2.3./2.4.3590-20);
- азык-төлек продуктлары һәм азык-төлек чималы бракеражы журналы;
-тиз бозыла торган азык-төлек продукциясе бракеражы журналы(5 кушымтаСанПин 2.3./2.4.3590-20);
- көнлек меню;
-әзерләнә торган ризыкларга технологик карталар;
-туклану рационын тикшереп тору ведомосте;
-азык-төлек продукциясенә керү турында документлар, азык-төлек продукциясенең сыйфатын раслый торган документлар (накладнойлар, сертификатлар һәм тәңгәллек декларациясе, сыйфат таныклыгы, ветеринария-санитария экспертизасы документлары һ.б.);
-җитештерү контроле программасы кысаларында лаборатор инструменталь тикшеренү уздыру турында гамәлдәге шартнамә булу;
-мәгариф учреждениесе җитәкчесе белән килештерелгән һәм туклануны оештыручы предприятие җитәкчесе тарафыннан расланган санитар-эпидемиологик таләпләргә һәм нормаларга җавап бирә торган якынча ике атналык меню булу;
- башкаручы турында мәгълүмат.

3.4.Мәктәп администрациясе сыйныф җитәкчеләре белән берлектә укучылар һәм ата-аналар (законлы вәкилләр) белән түләүле яисә түләүсез нигездә кайнар туклану оештыру максатында(башлангыч сыйныфларга, шулай ук социаль якланмаган гаилә балаларына) оештыру һәм аңлату эшләре алып бара.

3.5.Мәктәп администрациясе укучыларның кайнар ризык белән туклануында, сәламәт туклануның принципларын һәм санитария-гигиена нигезләрен үтәүдә, укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) белән консультация һәм аңлату эшләре алып баруга юнәлтелгән оештыру-идарә мәсьәләләрен хәл итүнетәэмин итә.

3.6.Барлык белем бирү учреждениесе укучыларын сәламәт туклану белән тәэмин итү кайнар ризыкны үз эченә алган төп (оештырылган) меню аша гамәлгә ашырылырга тиеш.

3.7.Якынча меню балаларга таләп ителә торган калориялелек, аксымнар, майлар, углеводлар, витаминнар һәм аларның нормаль физик һәм акыл үсеше өчен кирәкле микроэлементларны исәпкә алып, кимендә ике уку атнасына эшләнә.

3.7.1.Менюга,төп азык-төлек матдәләренең балаларны тукландыру рационында булу таләпләрен һәм нисбәтен үтәү шартларында,туклануның милли, конфессиональ үзенчәлекләрен исәпкә алып, төзәтмәләр кертү рөхсәт ителә.Дәвалау туклануына мохтаҗ укучылар өчен әлеге патология өчен расланган продуктлар җыелмасы нигезендә аерым меню төзелә(медицина учреждениесеннән белешмә һәм башка авыру вакытында тыелган продуктлар исемлеге булганда).

3.7.2.Менюда азык продукциясенең бер төрен, ашамлыкларны һәм кулинария әйберләрен, азык-төлек кыйммәтен исәпкә алып, азык-төлек продукциясен алмаштыру таблицасы нигезендә алмаштыру рөхсәт ителә(11 кушымтаСанПин 2.3./2.4.3590-20).

3.7.3.Менюда бер үк ашамлыкларны яки кулинар әйберләрне бер үк көнне яки алдагы 2-3 көндә кабатлау рөхсәт ителми.

3.7.4.Укучыларны ашату, пешерү, парда пешерү, томалап пешерү, төреп пешерү кебек ризыкларны әзерләүнең билгеле бер ысулларын куллануны һәм ярсыту үзлекләре булган ашамлыкларны кертмәүне күздә тоткан сәламәтлекне кайгырткан туклану принципларына туры килергә тиеш.

3.7.5.Балаларны туклануда биологик кыйммәтләрне тәэмин итү өчен файдаланырга киңәш ителә:

- югары азык-төлек кыйммәте булган продуктлар, шул исәптән баетылган продуктлар(макро-микронутриентлар, витаминнар, азык җепселләре һәм биологик актив матдәләр белән);
- май, шикәр һәм тоз күләме чикләнгән азык-төлек продуктлары;
- составындайод булган сөт, тоз, ипи.

3.7.6.Йогышлы һәм массакүләм йогышлы булмаган авырулар (агуланулар) килеп чыгуны һәм таралуны булдырмас өчен һәм сәламәтлекне кайгырткан туклану принциплары нигезендә әлеге санитария кагыйдәләре таләпләре буенча(6 нчы кушымтаСанПин 2.3./2.4.3590-20)азык продуктларын куллану һәм ризыклар һәм кулинар эшләнмәләр ясау рөхсәт ителми.

Маркировкасы булу Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, маркировкасы булмаган азык-төлек продукциясен сатарга рөхсәт ителми.

3.8.Укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү тиешле һөнәри квалификациясе булган, алдан (эшкә кергәндә) һәм әледән-әле медицина тикшерүе үтеп торучы, гигиена әзерлеге булган һәм 2 елга кимендә 1 тапкыр, билгеләнгән тәртиптә, персоналны гигиена буенча укыту программасы буенча яңадан әзерлек үткән,шәхси медицина кенәгәсе булганмәгариф учреждениесенең азык-төлек блогы хезмәткәрләре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Азык-төлек блогы персоналы тарафыннанашларны порционлаштыру һәм тарату бер тапкыр кулланыла торган перчаткалар киеп, кулинар эшләнмәләр (камыр ризыклары һ.б.) махсус инвентарь (кыскыч, көрәкчек, соус савыты, гарнир кашыгы һ. б.) кулланып, башкарыла.

3.9.Укучылар туклануында кулланыла торган азык-төлек чималының һәм азык-төлек продуктларының гигиена күрсәткечләре СанПин2.3/2.4.3590-20 таләпләренә туры килергә тиеш.

3.10.Кайнатылган су эчү режимын оештыргандаазык-төлек продукциясе белән эш итү өчен билгеләнгән материаллардан әзерләнгән савыт-саба, шулай ук чиста һәм файдаланылган савыт-сабаны кую өчен аерым маркировкаланган култабыннары; файдаланылган савыт-сабаны җыю өченбер тапкыр кулланыла торганконтейнерлар булырга тиеш.Упаковкадагы (шешәгә тутырылган) эчәргә яраклы суга товар турында документациясе булган очракта, аны балаларга бирергә рөхсәт ителә.

3.11.Туклануны оештыруга планлы контроль, чимал һәм әзер продукциянең сыйфатын контрольдә тоту Роспотребнадзор органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла

3.12.Укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру һәм аларның тулысынча ашавын тәэмин итүдә җаваплы зат булып гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесетора.

3.13.Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе боерыгы белән административ яки педагогик хезмәткәрләр арасыннан агымдагы уку елындаукучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру һәм аларның тулысынча ашавын тәэмин итүдә җаваплы затбилгеләнә.

3.14.Гомуми белем бирү учреждениесендә укучыларны ашату уку көннәрендә башкарыла. Ашау тәртибе мәгариф учреждениесе директоры тарафыннан раслана.

3.15. Ризыкһәр сыйныф укучыларына класс җитәкчесе тарафыннан алдан (48 сәгать алдан) бирелгән заявка нигезендә укучылар санынча бирелә.

## 4. ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ ТУКЛАНУЫН ОЕШТЫРУ ТӘРТИБЕ

4.1. Укучыларны ашату түләүсез һәм түләүле нигездә оештырыла.

4.2.1-4 сыйныф укучыларын кайнар аш белән тәэмин итү мәҗбүри тәртиптә, бюджет акчалары хисабына, түләүсез нигездә оештырыла.

4.3.Туклану рационнарының көндәлек менюлары мәктәп директоры белән килештерелә, ризыкларның күләме һәм кулинария әйберләренең исемнәре күрсәтелгән меню төшке аш залына эленә.

4.4.Балаларны туклandыру, шул исәптән меню турында мәгълүмат ата-аналарга һәм балаларга теләсә нинди үтемле ысул белән җиткерелә (төшке аш залында, һәркем карый алырлык урында мәгълүмат тактасында (стендта), гомуми белем бирү учреждениесе сайтында урнаштырыла).

4.5.Укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү класслары белән, уку дәресләре режимы нигезендә, кимендә 20 минутлык тәнәфесләрдә оештырыла. Беренче сменада укучылар икенче яки өченче тәнәфесләрдә иртәнге аш белән тәэмин ителәләр.

4.6.Мәктәп укучылары директор раслаган график буенча туклана. Азык-төлек блогының эш режимы учреждениенең эш режимы белән туры китерелә.

4.7.Һәр класс укучылары өчен ризык класс җитәкчесе тарафыннан алдан (48 сәгать алдан) бирелгән укучылар санына карап бирелә. Гаризаны формалаштыргандакласс җитәкчесе ата-аналарның (законлы вәкилләр) баланыңдәресләрне калдырачагы турында хәбәренисәпкә ала.

4.7.1.Әгәр бала нигезле сәбәпләр нәтиҗәсендә, ата-аналары (законлы вәкилләр) түләгән суммага ашамаса, фактта файдаланылмаган финанс чаралары киләсе айга укучының туклану бәясе исәбенә күчә.

4.8.Укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру өстәлне алдан әзерләп кую юлы белән башкарыла, 14 яшьтән өлкәнрәк кизү торучы балалар,кизү торучы укытучы җитәкчелегендә, тәнәфескә чыгарга 7-10 минут кала өстәлгә ризыкларны китереп куя. Һәр сыйныфка билгеле бер төшке аш өстәлләре беркетелә.

4.9.Мәктәп буенча җаваплы кизү торучы укучыларны сыйныф җитәкчеләре, педагоглар белән бергә аш бүлмәсенә озата. Сыйныф җитәкчеләре, педагоглар ашханәгә бару режимын, җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итәләр һәм ашханә хезмәткәрләренә туклануны оештыруда ярдәм итәләр, ашар алдыннан укучыларның шәхси гигиена таләпләрен үтәвен контрольдә тоталар.

4.10.Азык әзерләүне яхшырту һәм сыйфатны күтәрү максатыннан, белем бирү учреждениесендә мәктәп директоры боерыгы буенча бракераж комиссиясе

төзелә. Өч кешедән торган бракераж комиссиясе составына медицина хезмәткәре (штатта булган очракта) яки махсус җаваплы җаваплы зат; производство мөдире; туклануга җаваплы зат керә.

4.10.1. Бракераж комиссиясенең вәкаләтләре:

- азык-төлек продуктларын ташыган, китергән һәм бушаткан вакытта санитар-гигиена нормаларының үтәлешен контрольдә тота;

- склад бүлмәләренең һәм азык-төлекне саклау өчен башка бүлмәләрнең яраклылыгын, шулай ук аларның азык-төлекне саклау шартларын тикшерә;

- азык-төлек продуктларын сату срокларын һәм азык әзерләү сыйфатын контрольдә тота;

- ризыкның төп азык-төлек матдәләрендә балаларның физиологик ихтыяҗларына туры килүен тикшерә;

- азык-төлек блогы хезмәткәрләренең шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәвен күзәтеп тора;

-әледән-әле төп продуктларны салганда катнаша, таратканда әзер ризыкларның авырлыгын һәм температурасын үлчи;

-әзер ризыкның сыйфатына(«Җәмәгать туклануы продукциясе сыйфатын органолептик бәяләү методы»ГОСТны билгеләү методы 31986-2012) органолептик бәя бирә, ягъни аның төсе, исе, тәме, консистенциясе, катылыгы, сусыллыгы һ. б.ны билгели.Бракераж нәтиҗәсе «Әзер азык-төлек продукциясе бракеражы журналы»нда тәкъдим ителә торган форма (4 нче кушымта СанПин 2.3./2.4.3590-20) нигезендә теркәлә,проба алганнан соң гына әзер азык бирелә;

- әзерләнгән ризык күләменең бер тапкыр бирелә торган порцияләр күләменә һәм балалар санына туры килүен тикшерә.

## 5. ТҮЛӘҮСЕЗ АШАТУ ТӘРТИБЕ

5.1.Башлангыч сыйныф укучылары,ата-аналар керемена бәйсез рәвештә, кайнар ризык белән бушлай тәэмин ителә. Моның өчен ата-аналар(законлы вәкилләр) язмача гариза бирергә тиеш;

5.2. Урта һәм өлкән сыйныфларда белем алучы укучыларга адреслы, максатчан ярдәм күрсәтү ниятеннән түләүсез туклану хокукы бирә торган ташламалы категорияләр билгеләнә.

Ташламалы категорияләргә керә:

- җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган, баласына «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән айлык пособие алучылар булып тора торган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар (Республика матди ярдәм үзәгенең Зәй муниципаль районындагы 20нче бүлекчәсе реестры нигезендә);

- җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган, балаларына «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән айлык пособие алучы булып тора торган күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар (Республика матди ярдәм үзәгенең Зәй муниципаль районындагы 20нче бүлекчәсе реестры нигезендә);

- өйдә яки мәгариф оешмаларында белем алучы сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар.

Урта һәм өлкән сыйныфларда укучы балалары өчен (ташламалы категория) ташламалы туклану алу өчен ата-аналарга түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

- Җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган, баласына «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән айлык пособие алучылар булып тора торган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар өчен:
- ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) язмача гариза;
- Җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган, балаларына «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән айлык пособие алучы булып тора торган күпбалалы гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар өчен:
- күпбалалы гаилә таныклыгы;
-"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль Законның 79 статьясы 7 өлеше нигезендә сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән (ОВЗ) статусы белән өйдә белем алучы инвалид балалар коры паек белән тәэмин ителергә яисә акчалата эквивалентта ашау өчен компенсация алырга тиешләр:
- ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) язмача гариза;
- баланың инвалид булуы турында белешмә (белешмә күчермәсе);
- «Зәй үзәк район хастаханәсе» ДАССУ табиблык комиссиясе белешмәсе;
- психологик-медик-педагогик консультация бәяләмәсе.
- Белем бирү оешмаларында укучы сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән (ОВЗ) статуслы инвалид балалар:
- ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) язмача гариза;
- баланың инвалид булуы турында белешмә (белешмә күчермәсе);

5.3.Әлеге нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән социаль якланмаган гаиләләрдәге балаларны бушлай ашатуны финанс белән тәэмин итү бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

5.4.Ата-аналар (законлы вәкилләр) түләүсез туклану белән тәэмин итүне туктатуга китерә торган шартлар барлыкка килү турында мәгълүматны тиз арада җиткерергә тиеш.Бушлай туклану белән тәэмин итүне туктатуга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, гомуми белем бирү учреждениесе бу турыда мәгълүм булганнан соң икенче көндә укучыны түләүсез ашатуны туктата.

5.5. Гомуми белем бирү учреждениесе югарыда китерелгән категориягә керүче укучыларга бушлай ризык бирүдән түбәндәге сәбәпләр буенча баш тартырга хокуклы:алар тарафыннан әлеге нигезләмәнең 5.2 пунктында каралган документларны тапшырмау һәм/яки Республика матди ярдәм үзәгенең Зәй муниципаль районындагы 20 нче бүлеге тарафыннан җибәрелгән реестрда булмау.

5.6.Әлеге карарның 5.2 пунктында санап үтелгән укучыларның туклануын

оештыру өчен гомуми белем бирү оешмаларында комиссия төзелә, аның составына директор, педагогик хезмәткәрләр арасыннан укучыларның туклануын оештыру өчен җаваплы зат һәм ата-аналар комитеты вәкилләре керә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким булырга тиеш түгел.
Комиссия карый:
- ата-аналар биргән гаризаларны;
- республика матди ярдәм үзәгенең Зәй муниципаль районындагы 20нче бүлекчәсеннән җибәрелгән реестрны.
5.7. Бушлай туклану хокукына ия булган гомуми белем бирү учреждениесе укучылары исемлеге директор боерыгы белән раслана.

5.8.Бушлай тукланучы укучыларның исемлекләрен алга таба үзгәртү директор боерыклары белән раслана.

## 6.ТҮЛӘҮЛЕ ТУКЛАНУНЫ ОЕШТЫРУ СИСТЕМАСЫ

6.1. Түләүле туклану ташламалары булмаган укучылар өчен оештырыла.

6.2.Гомуми белем бирү учреждениесендә укучыларны кайнар ризык белән тәэмин иткән өчен түләү ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан гомуми белем бирү учреждениесе белән банклар арасында төзелгән килешү нигезендә муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең исәп-хисап счетларына кертелә һәм ул алдагы айга һәр айның 20 числосыннан да соңга калмыйча тиешле гомуми белем бирү учреждениесенең шәхси счетына күчерелә.

6.3.Туклануны финанслар белән тәэмин итү
ата-аналар средстволары;
- бюджет акчаларыхисабына гамәлгә ашырыла:

6.4.Ата-аналар түләве, гомуми белем бирү учреждениесендә бала булмаган түбәндәге очраклардан тыш, барлык очракларда да тулы күләмдә алына:
- бала авыру сәбәпле дәрес калдыру (бирелгән медицина белешмәсе нигезендә);
- карантин сәбәпле дәрес калдыру;
- башка җитди сәбәпләр аркасында (бирелгән документлар нигезендә).

6.5. Укучылар җитди сәбәпләрсез мәктәпкә килмәгәндә һәм мәктәпкә килмәве турында бер көн алдан язмача яки телдән хәбәр итмәгәндә, калдырылган беренче көн өчен ашау өчен ата-аналар түләве тулы күләмдә алына.

6.6.Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе баланың ата-анасына (законлы вәкиленә) туклану өчен түләү реквизитларын үзгәртү турында вакытында (3 эш көне эчендә) хәбәр итәргә тиеш.

## 7. ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНДӘ КАЙНАР РИЗЫК БЕЛӘН ТУКЛАНУНЫ ОЕШТЫРУГА КОНТРОЛЬ

7.1.Гомуми белем бирү учреждениесенең эшен контрольдә тоту администрация һәм укучыларның туклануын оештыруны контрольдә тоту буенча иҗтимагый комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Әзер продукциянең бракеражы бракераж комиссиясе тарафыннан алына.

Укучыларның туклануын оештыруны контрольдә тоту буенча җәмәгать комиссиясе администрация, педагогик хезмәткәрләр, медицина хезмәткәрләре, укучылар һәм ата-аналар арасыннан, кадрлар ротациясе принцибын исәпкә

алып,мәктәп директоры приказы белән төзелә.Приказның күчермәсе ашханә администрациясенә тапшырыла.Укучыларның туклануын оештыруны контрольдә тоту буенча иҗтимагый комиссия әледән-әле (кварталга кимендә 1 мәртәбә) директор каршындагы киңәшмәдә, инструктив-методик киңәшмәләрдә, педагогик советта әлеге йөкләмәләрне тикшереп тору һәм үтәү эше турында хисап тота.

7.2. Азык әзерләү технологиясен көн саен бракераж комиссиясе тикшерә.

7.3.Мәктәптә туклануны оештыруны контрольдә тоту комиссиясе составы һәр уку елы башында мәктәп директоры тарафыннан раслана.

7.4.Медицина хезмәткәрләре гомуми белем бирү учреждениесендә туклануны оештыруны, шул исәптән килә торган продуктларның сыйфатын, ризык әзерләгәндә продукция салуның дөреслеген һәм ризык әзерләүне күзәтергә тиеш.

7.5.Әзер ризык проба алынганнан соң гына бирелә. Органолептик күрсәткечләр буенча ризыксыйфатын бәяләүне бракераж комиссиясе үткәрә (проба ризык әзерләнә торган савытлардан турыдан-туры алына).

7.6.Саклауның махсус шартлары таләп итеглә торган тиз бозыла торган азык-төлек продуктларын саклау шартларын һәм срокларын үтәүне, сыйфатны һәм куркынычсызлыкны тикшереп тору максатында, термометрлар кулланып (терекөмешлеләрдән тыш) суыткыч җайланмада саклауның температура режимнарына контроль уздырыла.

7.7.Әзер азык-төлек продукциясенең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын контрольдә тоту максатында азык-төлек продуктларының һәр партиясеннән тәүлеклек проба алынырга тиеш.

Тәүлеклек проба азык-төлек блогы хезмәткәре (пешекче) тарафыннан махсус билгеләнгән зарарсызландырылган һәм маркировкаланган савытларга (тыгыз ябыла торган) һәр ризыктан һәм (яки) кулинария әйберләреннән аерым алына.Салкын кабымлыклар, беренче ашлар, гарнирлар һәм эчемлекләр (өченче ашлар) кимендә 100 грамм алынырга тиеш.Порцияле ашлар, биточкалар, котлетлар, сырниклар, коймаклар, казылык, бутербродлар тулысынча (бер порция күләмендә) алынырга тиеш.

Тәүлеклек пробалар 48 сәгатьтән дә ким булмаган срокта /температурасы +2 С тан +6 С ка кадәр булган суыткычтасакланырга тиеш.

7.8.Гомуми белем бирү учреждениесендә сәламәт туклану күнекмәләрен һәм культурасын формалаштыру, табын яны этикасы, алиментар-бәйле авыруларны, азык-төлек белән агулануларны һәм йогышлы авыруларны профилактикалау буенча эш (лекцияләр, семинарлар, эшлекле уеннар, викториналар, Сәламәтлек көне) оештырырга киңәш ителә.

## 8. ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БАЛАЛАРНЫ КАЙНАР РИЗЫК БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮНЕ ОЕШТЫРУГА АТА-АНАЛАР КОНТРОЛЕ

8.1.Укучыларның туклануын оештыруга ата-аналар контроле буенча чаралар үткәрү тәртибен, шул исәптәнашау-эчү бүлмәсенә укучыларның законлы вәкилләренең керү тәртибен регламентлаучыны,гомуми белем бирү учреждениесенең локаль норматив акты белән регламентларга киңәш ителә.

8.2.Ата-аналар контролен оештыру ата-аналар һәм балалар арасында анкеталау формасында(1 нче кушымта «МР 2.4.018-20») һәм гомуммәктәп комиссиясе эшендә катнашу рәвешендә(2 нче кушымта«МР 2.4.018-20») гамәлгә ашырыла ала.Тикшерү нәтиҗәләре буенча ата-аналарның гомуми җыелышларында фикер алышулар үткәрелә һәм алар белем бирү оешмасы администрациясенә, туклану операторына, контроль (күзәтчелек) органнарына мөрәҗәгать итү өчен нигез була алалар.

## 9. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

9.1.Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы норматив актлары, федераль санитар кагыйдәләр һәм нормалар, белем бирү учреждениесе уставы һәм әлеге нигезләмә нигезендә укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруда һәм аларның барысының да кайнар ризык ашавы өчен җаваплы зат булып тора.

**9.2. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе бурычлы:**

- «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт санитар-эпидемиологик нормалаштыруы турында нигезләмәләр", Санитар кагыйдәләр - СП-1.1.1058-01, СанПин 2.3/2.4.3590-20 нигезендәҗитештерү контроле программасын эшләргә;
- белем бирү учреждениесендә кайнар ашны оештыру өчен җаваплы кешеләрне билгеләргә: белем бирү учреждениесе администрациясе; сыйныф җитәкчесе; медицина хезмәткәре, ашханә мөдиреарасыннан туклану буенча җаваплыны;
- **азык-төлек блогы хезмәткәре гаебе белән җитештерү контроле программасы кысаларында лаборатор һәм инструменталь тикшеренүләрнең нәтиҗәләре канәгатьләнмәслек булса, хокук бозуларны бетерүгә һәм аларның барлыкка килүенә юл куймауга, белем бирү учреждениесенең азык-төлек блогының гаепле хезмәткәре хисабына лаборатор тикшеренүләр үткәрүгә юнәлтелгән чаралар күрергә.**

**9.3. Туклану буенча җаваплы зат бурычлы:**

- ата-ана түләвенең дөрес һәм үз вакытында кертелүен контрольдә тотарга;
- класс ата-аналар җыелышларында, ата-аналарның гомуми җыелышы утырышларында укучыларны ашатуны оештыру мәсьәләләрен күтәрергә;
- сыйныф җитәкчеләре эшчәнлеген координацияләргә һәм контрольдә тотарга;
- укучыларның ашханәгә фактта йөрешен исәпкә алуны тәэмин итәргә, барлык укучыларның да туклануын тәэмин итәргә, класслар буенча фактта алынган кайнар ризык санын исәпкә алуның көндәлек тәртибен контрольдә тотарга;
- укучыларның туклануына акча исәпләү өчен укучыларның исемлекләрен бухгалтериягә тапшырырга;
- әлеге нигезләмәдә каралган очракларда, балаларын түләүсез ашату мөмкинлеге турында ата-аналарга (законлы вәкилләргә) хәбәр итәргә;
- түләүсез ашаучы укучылар исемлегендә үзгәрешләр турында мәгълүматны үз вакытында тапшырырга;
- ай саен алдагы айның 3 числосына кадәр «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә укучыларны тукландыру буенча финанс хисабын тапшырырга;

- стендта менюның булуын тикшерергә;
- әзерләнгән ризыкның меню буенча туры килүен тикшерергә;
- тукланучылар саны буенча заявкаларны үз вакытында тапшыруны контрольдә тотарга;
- әзер ризыкныңтемпературасын һәм авырлыгын тикшерергә;
- туклану культурасын формалаштыру буенча мәгариф учреждениесендә эшне координацияләргә;
- укучылар арасында ризык сыйфаты белән канәгать булу мониторингын тормышка ашырырга;
- туклануны оештыруны яхшырту буенча тәкъдимнәр кертергә;
- укучыларның дөрес һәм сәламәт туклануына багышланган оештыру чаралары үткәрергә.

**9.4. Белем бирү учреждениесенең класс җитәкчесе бурычлы:**

- белем бирү учреждениесендә туклануны оештыру тәртибе турында ата-аналарга (законлы вәкилләргә) җиткерергә;
- балаларның ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) кайнар ризык белән тәэмин итүгә гариза җыярга, алга таба ул аларны мәгариф учреждениесе администрациясенә тапшыра. Гаризада кайнар туклану бирүнең ничә мәртәбә булуы һәм төрләре (иртәнге һәм (яисә) төшке аш төрләре) билгеләнә;
- мәгариф учреждениесе администрациясенәукучыларны ташламалы тукландыру өчен социаль педагог, сыйныф җитәкчесе, тәрбия эше буенча директор урынбасары составындагы комиссиянең торак-көнкүреш шартларын тикшерү актын тапшырырга;
- 48 сәгать эчендә уку көненә туклануны оештыру өчен мәктәп ашханәсенә укучылар саны буенча заявканы бирергә;
- бирелгән гаризаны көн саен 8.30 сәгатькә кадәр төгәлләштерергә (иртәнге аш/көндезге аш/өстәмә тукланугабер сәгать кала);
- укучылар тарфыннан алынган кайнар тукланунын көндәлек исәпкә алу табелен алып барырга;
- гомуми белем бирү учреждениесенең туклану буенча җаваплы затынафактта ашаган укучылар саны турында атнага бер тапкырдан да ким булмаган мәгълүмат бирергә;
- үз компетенциясе өлешендә мәктәптә туклануны оештыруны мониторинглауны башкарырга;
- укучыларның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, балансль һәм рациональ туклануга булган ихтыяҗны формалаштыруга юнәлдерелгән чараларны тәрбия эше планына кертергә, укучыларның тулы кыйммәтле туклануын тәэмин итү мәсьәләләрен ата-аналар җыелышларында фикер алышуга чыгарырга;
- педагогиксоветы утырышларында, директор үткәргән җыелышларда туклануны яхшырту буенча тәкъдимнәр кертергә.

**9.5. Медицина хезмәткәре (булган очракта) яисә билгеләнгән җаваплы зат бурычлы:**

- СанПин 2.3/2.4.3590-20,СанПин 2.4.2.2821-10,«МР 2.4.0179-20», «МР 2.4.0180-20» нормалары үтәлешенә контрольне алып барырга;

- көн саен эш башланыр алдыннан азык-төлек блогы хезмәткәрләрененңкул тиресендә эренле авырулар һәм гәүдәнең ачык өлешләрендә йогышлы авырулар билгеләре булу-булмауга тикшерү уздырырга.Тикшерү нәтиҗәләре гигиена журналына язылырга тиеш(1 кушымтаСанПин 2.3./2.4.3590-20).Карау көненә журналда билгеләнгән хезмәткәрләр исемлеге бу көнгә хезмәткәрләр санына туры килергә тиеш;
- туклануны оештыруны, шул исәптән керә торган продуктларның сыйфатын, ризык әзерләү өчен продуктлар салуның дөреслеген һәм ризык әзерләү барышын күзәтергә;
-көн саен әзер ризыклардан бракераж алу комиссиясе эшендә катнашырга;
-төп продуктларны салганда вакыт-вакыт катнашырга, әзер ашамлыкларның чыгуын һәм температурасын тикшерергә;
- тәүлеклек проба алуның дөреслеген һәм аның саклану шартларын тикшереп торырга;
- куллану буенча инструкцияләр нигезендә дезинфекция чаралары белән савыт-саба һәм өстәл приборларын юу кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тотарга;
- ашар алдыннан укучыларның кул гигиенасын үтәүләрен контрольдә тотарга.

**9.6. Ашханә мөдире бурычлы:**

1. СанПин 2.3/2.4.3590-20,«МР 2.4.0179-20»,«МР 2.4.0180-20» нормаларын сакларга;
2. Маркировкалар һәм товар турында документациясе булгандаазык-төлек продукциясен, шул исәптән азык-төлек чималын кабул итә башларга;
3. Азык-төлек продуктларының саны һәм сыйфаты сакланышы, саклау сроклары һәм шартлары үтәлеше, төргәкләү ярлыклары һәм норматив документлар турында белешмәләрнең булуы өчен җаваплылык тотарга;
4. Продукция әзерләгәндә технологик картага таянып эш итәргә;
5. Туклануны оештыру буенча хезмәт күрсәтүче оешмага тукланучылар саны турында үз вакытында заявка бирергә;
6. Азык-төлек әзерләгәндә һәм аларны эшкәрткәндә санитария кагыйдәләрен һәм нормаларын үтәүне тәэмин итү (әзер һәм чи продукция өчен бүлү инвентареннанфайдалану (маркировкалау буенча) һәм җитештерү цехларында (зоналарда, участокларда) аерым саклау);
7. Эш урынында чисталыкны һәм тәртипне, инструкция нигезендә дезинфекция чараларын үз вакытында әзерләү һәм куллану тәртибен күзәтеп торырга;
7. Әзерләнә торган ризыкларның сыйфаты һәм санына контрольне тәэмин итү;
8. Көн саен әзер ризык әзерләү партияләре буенча суыткычка тәүлеклек пробаларны куярга;
9. Ашханәдә җитәкче белән килештерелгән көндәлек менюны эләргә;
10. Меню нигезендә көн саен контроль ризыкны кую;
11.Туклану хезмәтләрен оештыручы предприятиегә товар хисапларын (көндәлек туклану, меню, туклану талоннары реестрларын кушып) үз вакытында тутырып, тапшырырга;
12. Савыт-саба һәм инвентарьны маркировкалауны оештырырга;
13.Ашханә хезмәткәрләренең эш урынында махсус кием һәм махсус баш киеменнән, әзер ризыкларны таратканда бер мәртәбә киелә торган перчаткалардан булуынконтрольдә тотарга;

14. Эш көне ахырында барлык савыт-саба, ашханә приборлары, култабыннар савыт-саба юу машиналарында дезинфекцияләүне тәэмин итүче режимнар һәм максималь температура режимнарын кулланып юыла.

Савыт-саба юу машинасы булмаганда, куллану инструкцияләре нигезендә, бөтен савыт-саба һәм ашханә приборлары, дезинфекцияләү чаралары белән эшкәртелеп, кулдан юылырга тиеш.

15. СанПиН 2.3/2.4.3590-20 нигезендәкөн саен кирәкле документларны тутырырга һәм алып барырга.

**9.7. Туклануны оештыручы предприятие җаваплы:**

- туклануны оештыручы предприятие җитәкчесе тарафыннан расланган ике атналык меню төзүгә;
- атналык һәм бер көнлек меню төзүгә;
- азык-төлек продуктларын махсус җиһазландырылган транспорт белән китерү;
- кергән чималны контрольдә тотуны тәэмин итүгә: сыйфат,тәңгәллек сертификаты булу, сыйфат турында таныклама;
- гамәлгә ашыра:

1.) Санитар контрольне;
2.) Технологик контрольне;
3.) Ветеринария контролен;
4.) Җитештерү контроле кысаларында төзелгән контракт нигезендә лаборатория-инструменталь контрольне.

**9.8.Укучыларның әти-әниләре (законлы вәкилләре):**

- тиешле документларны теркәп, ташламалы туклануга гариза тапшыралар;
- ай саен, һәр айның 20 числосыннан да соңга калмыйча, киләсе айга туклану өчен акча кертәләр;
- сыйныф җитәкчесенә түләү турында түләү порučениесе күчермәсен тапшыралар;
-сыйныф җитәкчесенә баланың авыруы турында яисә гомуми белем бирү учреждениесендә ул фактта булмаган чорда аны тукланучылар исәбеннән төшерү өчен, вакытлыча булмавы турында үз вакытында хәбәр итәргә, шулай ук медицина хезмәткәрен һәм сыйныф җитәкчесен балада туклану продуктларына аллергия реакцияләре булу турында кисәтергә бурычлы(медицина учреждениесеннән белешмә);
- ашказаны-эчәклек тракты авырулары булганда диетик туклану таләп ителгәндә белешмә бирәләр һәм башка авыру вакытында рөхсәт ителмәгән азык-төлек исемлеген тапшыралар;
- сәламәт яшәү рәвеше һәм дөрес туклану күнекмәләрен тәрбияләү буенча үз балалары белән аңлату эшләре алып баралар;
- укучыларның туклануын оештыруны яхшырту буенча тәкъдимнәр кертергә хокуклы;
- ике атналык һәм көндәлек меню, укучыларның туклануын оештыруга акча исәп-хисаплары белән танышырга хокуклы.

9.9. Мәктәп ашханәсендә бракераж комиссиясе, иҗтимагый комиссия составы, меню, ашханә буенча классларның дежур тору графигы, ашханә буенча кизү тору вакыты, туклану культурасы буенча материаллар, фикерләр һәм тәкъдимнәр китабы белән мәгълүмат стенды күренә торган урынга элеп куела.

## 10. АТА-АНАЛАР ТҮЛӘВЕНЕҢ ҮЗ ВАКЫТЫНДА КЕРҮЕН ҺӘМ ФИНАНС ЧАРАЛАРЫНЫҢ МАКСАТЧАН ТОТЫЛУЫН КОНТРОЛЬДӘ ТОТУНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ

10.1.Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе контрольдә тота:

- ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан ата-ана түләвенең дөрес итеп һәм үз вакытында кертелүен;
- укучыларны кайнар аш белән тәэмин итү өчен кергән бюджет акчаларын тотуны.

10.2. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә туклануга бюджет акчаларын максатчан сарыф итүне "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе"муниципаль казна учреждениесе контрольдә тота.

## 11. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

11.1. Укучыларның туклануын оештыруны камилләштерү максатларында гомуми белем бирү оешмасы:

- уку эшчәнлеге кысаларында укучыларның туклану культурасын күтәрү буенча даими мәгълүмати-агарту эшен оештыра;
- туклану культурасын формалаштыру мәсьәләләренә багышланган мәгълүмат стендларын рәсмиләштерә һәм даими яңартып тора;
- укучыларның өй шартларында туклану режимын һәм рационын, гомуми белем бирү оешмасының эш режимын, мәктәп ашханәсенең сыйдыру сәләтен исәпкә алып, укучыларның туклануын яхшырту мәсьәләләрен хәл итүдә ата-аналарның ихтыяҗларын һәм мөмкинлекләрен өйрәнә;
- ата-аналар (законлы вәкилләр) белән системалы эш оештыра, кеше сәламәтлеген формалаштыруда тукलануның роле, көндәлек баланслы тукلануны тәэмин итү, туклану культурасын үстерү мәсьәләләренә багышланган әңгәмәләр, лекторийлар һәм башка чаралар үткәрә,ата-аналарны (законлы вәкилләрне) балалар белән ял оештыру һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, өй шартларында дөрес тукلануны пропагандалау буенча эшкә җәлеп итә;

тукلануны оештыруга мониторинг үткәрә һәм билгеләнгән сроклар һәм формалар нигезендә «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы, тукلануны оештыру мәсьәләсе буенча статистик күрсәткечләргә ия белешмәләрне үз вакытында җибәрә,тукلануны оештыру буенча белешмәләрне объектив һәм вакытында тапшыруны тәэмин итә.